***Аерым фәнннәрне тирәнтен өйрәтүче Питрәч беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе***

# *“Һөнәр сайлау “*

# *темасына 10 нчы сыйныфта( рус төркеме) татар теленнән ачык дәрес конспекты*

***Укытучы: ЧукуроваГ.И.***

**Дәреснең барышы**

**I. Дәресне оештыру.**

Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, кадерле укучылар! Утырыгыз. Дәресебезне башлыйбыз.

**II. Дәресне актуальләштерү**

1. Башта фонетик күнегү эшләп алыйк әле. Бүгенге дәрестә без күп кенә яңа сүзләр кулланачакбыз, аларның дөрес әйтелешенә ирешү өчен фонетик күнегү үткәрик,
   h - hө - hөнәр
   Җ- җа - җаваплы
   Ө- мө - мөмкинлек
   Ә- тә - тәкъдим итү
   Ү-тү – түләүле
   Ң - ңа - шуңа.

- Үткән дәрестә без сезнең белән hөнәр сайлау турында сөйләшә башладык. Әйдәгез әле, өй эшен тикшерик. Сез hөнәр исемнәре уйлап килергә тиеш идегез.

Сәүдәгә бәйле hөнәр исемнәре:

Икътисад;

Транспорт;

Авыл хуҗалыгы;

Мәгърифәт;

Сәнгать.

**III. Яңа дәрес материалы өстендә эш**

1. - Укучылар, һөнәр сайлау- һәркемнең тормышынла бик мөһим нәрсә ул. Моны раслап -“һөнәрле - үлмәс, һөнәрсез - көн күрмәс!” - диләр. Безнең дәресебезнең темасы: “һөнәр сайлау”.

2 . Дәресебезнең максаты: һөнәр сайлау турында сөйләшергә, фикер йөртергә, язарга өйрәнүне дәвам итү. Шулай ук без сезнең белән алдагы дәресләрдә сочинение язу өчен план да төзербез.

2. Моның өчен үткән дәресләрдә өйрәнгән һәм куллану өчен кирәк булачак сүзләрне кабатлыйбыз:

һөнәр сайлау - әһәмиятле - Җаваплы - Исәпкә алырга - Максатка ирешү - Омтыла - Шәхси пролема -

Киңәш бирәләр - Канәгать булырга - Эшкә урнаштырырга.

-Укучылар ә хәзер яңа сүзләр белән танышабыз.

3. Сүзлек эше

Үткән саен

Мөмкинлектән чыгып

Шактый кыен

Хәл итәргә

Төгәл.

4. - Ә хәзер яңа сүзләр белән җөмләләр төзик.

- Укучылар, ә хәзер китаптагы диалогны укып үзләштерик.

5. Әңгәмә.(Укучылар сорауларга җавап бирәләр, әңгәмә төзиләр)

-Бездә нинди профильләр бар?

-Нинди фәннәр укытыла?

-Ә сез нинди һөнәрләр беләсез?

-Хәзер нинди һөнәрләр популяр?

-Кайсы һөнәр сезгә бигрәк тә ошый?

-Сез кем булырга хылланасыз?

-Татарстанда нинди югары уку йортлары бар?

-Гаиләгездә нинди һөнәр кешеләре бар?

6. Сезгә өй эше итеп өстәмә иҗади бирем бирелгән иде.

7. (“Минем гаиләдәге һөнәр кешеләре”, яки “Әти-әниемнең һөнәре”) (1-2 сочинениене уку).

- Әбезнең районга нинди профессия кешеләре кирәк? Сезнең максат - укып бетереп, районга кайтып, аны алга җибәрү.

Укучылар без сезнең сочинениеләрдән кечкенә генә стенд төзеп, аңа исем куярбыз. Стендка исем сайлау өчен без өйрәнгән мәкальләрне искә төшерик. Кайсы туры килер икән?

8. Ә хәзер сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне рус теленә тәрҗемә итәрбез.

**IV. Дәрес материалын ныгыту.**

1. Укучылар, өстәлләрегездә яткан карточкаларыгызны алыгыз әле.(”һөнәр” темасына кагылышлы җөмләләрне төзеп әйтү, тәрҗемә итү).

- Укучылар, һөнәр сайлау темасын бик күп әсәрләрдән табарга мөмкин. Мәсәлән, Г.Әпсәләмов “Ак чәчәкләр” романында табиблар, Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” повестенда табиб, артист, укытучы, Г.Ахуновның “Хәзинә” романында нефтьчеләр турында язалар.

Укучылар, бу тема сезне дә борчый. Киләсе елда сез 11нче сыйныфта укыячаксыз. Димәк, һөнәр сайлау турында хәзердән үк уйларга кирәк. Киләсе дәресләрдә без “Кем булырга?” темасына сочинение язачакбыз. Ә бүгенге дәрестә сочинение өчен план төзербез.

3. Үткән дәресләрдә сез “Һөнәр сайлау кем эше?” - дигән сорауга 3 төрле фикер әйттегез:

һөнәр сайлау - шәхси проблема;

һөнәр сайлауга әти-әниләр җаваплы.

Бу мәсьәләне җәмгыять хәл итәргә тиеш.

4. Төркемнәргә бүленеп бу фикерне исбатлау.
5. Ял итү.
6. Нәтиҗәне язып, элеп кую.(План төзү)
7. Сорау-җавап формасында фикер алышу.

**V. Дәресне йомгаклау.**

1. -Укучылар, интернет буенча Оксанага иптәш кызыннан хат килгән. Ул - Җәмилә, Америкада яши. Хәзер шул хатны укыйм әле.

Сез бу кызга нинди киңәш бирерсез?

2. (Өй эше)

3. Без бүгенге дәрестә нәрсә өйрәндек?

(Йомгаклау)